**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президенты актларын әзерләү, бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү, Татарстан Республикасы законнары проектларын Татарстан Республикасы Президентына бирү тәртибенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Президенты актларын бастырып чыгару тәртибен камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты актларын әзерләү, бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү, Татарстан Республикасы законнары проектларын Татарстан Республикасы Президентына бирү тәртибе турында» 2004 елның 2 июнендәге ПУ-431 номерлы Указы (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-622 номерлы һәм 2014 елның 14 августындагы ПУ-788 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Президенты актларын әзерләү, бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү, Татарстан Республикасы законнары проектларын Татарстан Республикасы Президентына бирү тәртибенең 11 пунктына, икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасы Президенты актлары текстларын тулысынча «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналында бастырып чыгару яисә аларны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) беренче тапкыр урнаштыру (бастырып чыгару) рәсми рәвештә бастырып чыгару булып санала. Татарстан Республикасы Президентының кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләренә кагылышлы норматив характердагы указлары текстларын тулысынча беренче тапкыр «Хокукый мәгълүмат рәсми интернет-порталында» (www.pravo.gov.ru) урнаштыру (бастырып чыгару) шулай ук рәсми рәвештә бастырып чыгару булып санала.».

2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 ел, 20 февраль
№ ПУ-178

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ